РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№_135**

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 14 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану» муниципаль программасын әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
10.02.2020 елның 135 номерлы карарына
кушымта

# «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигый ресурсларын яңадан торгызу һәм куллану»

## муниципаль программасы

(алга таба – Программа)

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары | Хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең табигый мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү |
| Программаның бурычлары | 1. Әйләнә-тирә мохиткә агымдагы хуҗалык эшчәнлеге белән бәйле тискәре йогынтыны минимальләштерү.<br>2. Су объектларының пычрануын һәм чүпләнүен кисәтү. |
| Программаның максаты: | Гражданнарның экологик куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү, районның табигый ресурсларын саклау һәм куллану |
| Ярдәмче программалар исемлеге | Программа составында ярдәмче программалар юк |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Программаны финанс белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 1386,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 – 0 мең сум,<br>2019 – 6,0 мең сум,<br>2020 – 1380,0 мең сум<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | 1. Санкцияләнмәгән чүплекләр саны киму.<br>2. Каты көнкүреш калдыклары территориясе буйлап карталарга һәм бушату мәйданчыкларына чүп-чар ташучы транспортның (мусоровоз) технология нигезендә баруын яхшырту.<br>3. Кукмара ш. территориясенең экологик торышын яхшырту һәм экологик куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү.<br>4. Файдаланылмый торган мәйданнарны авыл хуҗалыгы производствосының чәчү әйләнешенә кайтару. |
| Җаваплы башкаручы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |

## 1. Кукмара муниципаль районының әйләнә-тирә мохите торышы характеристикасы

Кукмара муниципаль районы үсешенең төп юнәлешләренең берсе – халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү. Халыкның югары тормыш сыйфаты һәм сәламәтлеге, шулай ук муниципаль берәмлекнең тотрыклы икътисади үсеше табигый системаларны саклау һәм әйләнә-тирә мохитнең тиешле сыйфатын саклау шартларында гына тәэмин ителергә мөмкин. Моның өчен экология өлкәсендә әйләнә-тирә мохитне саклауга һәм табигый ресурслардан рациональ файдалануга юнәлтелгән бердәм сәясәт формалаштырырга һәм эзлекле рәвештә гамәлгә ашырырга кирәк.

Куллану калдыклары барлыкка килү күләмнәренең даими артуына үз вакытында чаралар күрмәү хәлне катлауландырырга мөмкин һәм якын киләчәктә, котылгысыз рәвештә, пычранган җир һәм су объектларының үсүенә һәм, нәтиҗә буларак, муниципаль берәмлек территориясенең санитар-эпидемиологик торышы начарлануга китерәчәк.

Кукмара муниципаль районы территориясендә экология проблемаларын перспективалы хәл итү программа-максатчан методны кулланып өзлексез һәм комплекслы якын килүне тәэмин итүне таләп итә.

Кукмара муниципаль районында санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләргә чыгарыла торган көнкүреш калдыклары белән эш итү проблемасы кискен тора.

Санкцияләнмәгән чүп-чар чыгару, хәтта зур булмаган күләмдә дә, куркыныч экологик хәл тудыра, чөнки таркалу продуктлары җиргә тирән үтеп керә, һавага бүленеп чыга, суга эләгә. Шулай итеп, чүплекләр булу РФ Конституциясенең һәркемнең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукы билгеләнгән 42 статьясын боза.

Санкцияләнмәгән чүплекләр чүп-чар янган очракта атмосферага зарарлы матдәләр генә түгел, ә агулы матдәләр дә чыгуы белән куркыныч. Моннан тыш, алар урман янгыннары килеп чыгуга сәбәп булып тора.

Табигатьне кеше эшчәнлеге калдыкларының йогынтысыннан саклау проблемасы көннән-көн актуальләшә бара.

Санкцияләнмәгән чүплекләр махсус полигоннар категориясенә керми һәм СанПиН 2.1.7.1038-01 таләпләренә туры килми, полигонны урнаштыру өчен участок расланган генераль план яисә торак пунктны планлаштыру һәм төзү

проекты нигезендә бүленергә тиеш, санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмәсе булырга тиеш. Санкцияләнмәгән чүплекләр бетерелергә тиеш.

Кеше сәламәтлеге өчен яшәү тирәлегенең иминлеген тәэмин итүнең санитар-эпидемиологик таләпләре нигезендә җитештерү һәм куллану калдыклары халык сәламәтлеге һәм яшәү тирәлеге өчен куркынычсыз шартларда һәм ысуллар белән җыелырга, файдаланырга, зарарсызландырылырга, ташылырга, сакланырга һәм күмелергә тиеш.

Юк ителгән санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерүне контрольдә тоту өчен, тәртип бозучыларны ачыклау максатыннан, видеокүзәтү системасы урнаштырылачак.

2018 – 2020 елларда махсус контейнер мәйданчыкларын норма буенча билгеләнгән хәлгә китерү буенча эш дәвам итәчәк.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, тупланган экологик зыянны бәяләү һәм бетерү проблемасын хәл итү – проблеманы хәл итү өчен шактый чыгымнар таләп итә торган озак сроклы процесс.

Су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү проблемаларын хәл итү аерым игътибар таләп итә. Программаның элеге юнәлешенең төп бурычы – кече елгаларның һәм күлләрнең экологик торышын торгызу, алар территорияләрне санитар чистартуның Генераль схемасы белән карала. Туфракның уңдырышлылыгын торгызу.

## 2.Муниципаль программаның төп максатлары һәм бурычлары, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә үсеш фаразлары

Муниципаль программаның максаты – хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең табигый мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру кысаларында куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк булачак:

1. Агымдагы хуҗалык эшчәнлеге белән бәйле әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны минимальләштерү.

2. Су объектларының пычрануын һәм чүпләнүен кисәтү.

3. Авыл хуҗалыгы әйләнешенә кайтару максаты белән туфракның уңдырышлылыгын торгызу.

Программа социаль характерда. Муниципаль программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге планлаштырылган программа чараларын үтәү юлы белән Кукмара муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше максатларына һәм бурычларына туры килә торган максатларга һәм бурычларга ирешүдән гыйбарәт.

Муниципаль программаның экологик нәтиҗәлелеге әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны эксплуатацияләү объектларының кимүе белән бәйле:

- әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынтыны киметү;
- җирләрнең пычрануын киметү;
- Кукмара муниципаль районы территориясендә экологик куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү.

## 3. Муниципаль программаны финанслау күләмнәре турында белешмәләр

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләме 1 386,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2018 ел – 0 мең сум,

2019 ел – 6,0 мең сум ,

2020 ел – 1 380,0 мең сум.

## 4. Рисклар белән идарә итү механизмнарын тасвирлау

Муниципаль программаның рискларын һәм алар белән идарә итү механизмнарын тасвирлау таблицада күрсәтелгән.

Таблица

| № т/б | Риск төре | Риск факторларын билгеләү | Рисклар белән идарә итү чаралары |
|---|---|---|---|
| 1 | Финанс ягыннан (тышкы) | Финанс ресурслары белән тәэмин ителмәгән яңа чыгым йөкләмәләрен кертү буенча карарлар кабул итү; Җәлеп ителә торган бюджет ресурслары буенча процент ставкасы үсеше; Төрле дәрәҗәләрдәге бюджетлар арасында вәкаләтләр һәм (яки) финанс агымнары балансын үзгәртүне күздә тоткан федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге яңа норматив актларны кабул итү. | Кукмара муниципаль районының закон белән билгеләнгән бюджет кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итүче озак сроклы бюджет стратегиясен раслау, шулай ук Кукмара муниципаль районының муниципаль программаларын тормышка ашыруга җирле бюджетның озак сроклы чорга иң чик чыгымнарын билгеләү һәм аларны чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет проектын формалаштырганда үтәү. |
| 2 | Хокукый (тышкы) | Бюджет һәм салым өлкәләрендә федераль һәм региональ законнар үзгәрү | Федераль һәм региональ законнар үзгәрүгә оператив җавап бирү |
| 3 | Социаль яктан «Кеше факторы») (эчке) | Муниципаль программа чараларын сыйфатсыз һәм (яки) вакытында үтәмәү | Хакимият органы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм җаваплылыгын арттыру максатыннан Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә башкарма органнары җитәкчеләренә карата санкцияләр куллану |